**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1814**
**17.03.2021**

Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3251 номерлы, 2017 елның 3 маендагы 2748 номерлы, 2017 елның 11 июлендәге 4092 номерлы, 2018 елның 21 декабрендәге 7675 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 3045 номерлы, 2020 елның 4 февралендәге 445 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.9 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, ст. 4563);»;

2) 2.5 пунктта икенче багананың соңгы абзацында «гаилә составы турында белешмә (гаилә составы һәм прописка турында йорт кенәгәсеннән өземтә» сүзләрен «торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 12 пункты;<br>181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов